**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.03.2015** № **09-16-33**

г. Казань

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы сатып алулар
буенча Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының
дәүләт гражданлык вазифасына билгеләнгәндә,
дәүләт хезмәткәрләре үзләренең, хатынының (иренең)
балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары
һәм милек характерындагы йөкләмәре турында белешмә
алып килеп бирергә тиешле дәүләт гражданлык хезмәте
вазифалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы , “Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 21 ноябрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә күзәтчелек хакында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Федераль дәүләт граждан хезмәте вазифасына билгеләнгәндә гражданнар һәм федераль дәүләт граждан хезмәте вазифасын биләгәндә федераль дәүләт хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазифалар исемлеген раслау турында” 2009 елның 18 маендагы 557 номерлы Россия Федерациясе Президентының Указы, “Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасына билгеләнгәндә, гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәте вазифасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазифалары исемлеген раслау турында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы һәм нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы сатып алулар Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасына дәүләт граждан билгеләнгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазифалар исемлеген расларга.

2. Аңлатма бирергә: дәүләт гражданлык вазифасына билгеләнгәндә исемлеккә кертелгән очракта, һәр ел саен керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәр турында белешмә бирү өчен, билгеләнгән вакыт эчендә үзенең чыгымнары, хатын яки иренең чыгымнары һәм балигъ булмаганы балаларның җир сатып алган, бүтән күчемсез милек, транспорт чаралары, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешманың устав (кушма) капиталында өлештә тору, пай өлешендә тору) булу очракларында, белешмәләр бирелергә тиешле ел алдыннан килгән календарь ел барышында үзе белән, хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балалары белән һәр килешү буенча (әгәр бар булган килешүләрнең суммасы, гражданинның һәм хатынының (иренең) ахыргы өч ел эчендәге бердәм керемнәр суммасынан артып киткән очракта), керемнәр чыганагы, шушы керемнәргә ясалган килешүләр белешмәдә күрсәтелергә тиешле.

3. Аңлатма бирергә: исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан, әгәр әлеге оешма дәүләт идарәсенең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфасы (хезмәттәге) таләпләренә кергән булса, таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белән дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә

хезмәт шартнамәсе шартларында оешмада вазыйфа биләргә яисә әлеге оешмага бер ай дәвамында граждан-хокук шартнамәсе (граждан-хокук шартнамәләре) шартларында йөз мең сумнан артык күләмдәге эш башкарырга хокуклы.

исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә әлеге боерыкның өченче пунктның 2-нче абзацында күрсәтелгән эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турындагы граждан-хокук шартнамәсен имзалаганда эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турында хәбәр итәргә тиеш.

исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге Боерыкның өченче пунктның 3-нче абзацында каралган таләпне үтәмәве әлеге граждан белән төзелгән эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) граждан-хокук шартнамәсен өзүгә китерә.

4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга тиеш.

5. “Татарстан Республикасының дәүләт сатып алулар идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле шулай ук дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалар исемлеген раслау турында” 2014 елның 09 гыйнварендәге №09-16-1 Татарстан Республикасының дәүләт сатып алулары идарәсе җитәкчесенең боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

6.Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны рәис урынбасары Абдуллин Айдар Мансур улына йөкләргә.

Рәис О.А.Редько

Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән расланган
2015 елның “ 10 ” 03
№09-16-33

**Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык вазифасына билгеләнгәндә, дәүләт хезмәткәрләре үзләренең, хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары һәм милек характерындагы йөкләмәре турында белешмә алып килеп бирергә тиешле дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

| № | Вазыйфа |
|---|---|
| 1. | Рәисе урынбасары |
| 2 | Эшләр белән идарә итүче |
| | |
| Үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | Әйдәүче консультант |
| 5. | 1нче разрядлы белгече |
| | |
| Үзәкләштерелгән сатып алуларны анализлау һәм тәэмин итү бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | 1нче разрядлы өлкән белгеч |
| 5. | Әйдәүче белгеч - эксперт |

| | |
|---|---|
| | |
| Дәүләт контрактларын башкару бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | 1нче разрядлы белгече |
| | |
| Сатып алуларны методик тәэмин итү бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | Әйдәүче консультант |
| 5. | 1нче разрядлы белгече |
| | |
| 1. | Әйдәүче киңәшче |
| 2. | Әйдәүче белгеч |